МИНИСТЕРСТВО
ПРОМЫШЛЕННОСТИ И ТОРГОВЛИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
СӘНӘГАТЬ ҺӘМ СӘҮДӘ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** | Казан шәһәре | **БОЕРЫК**

07.07.2016 | №165-ОД

**Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының 2014 елның 18 апрелендәге 91-ОД номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының җылылык челтәрләре буенча җылылык энергиясен, җылылык китерү матдәсен тапшырганда технологик югалту нормативларын раслау буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының норматив хокукый актларын законга туры китерү максатларында

б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының 2014 елның 18 апрелендәге 91-ОД номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының 2015 елның 4 сентябрендәге 277-ОД номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының җылылык челтәрләре буенча җылылык энергиясен, җылылык китерү матдәсен тапшырганда технологик югалту нормативларын раслау буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.
2. Әлеге Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны энергетика мәсьәләләрен алып баручы министр урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары –
министр А.Ә.Кәримов

Татарстан Республикасы
Сәнәгать һәм сәүдә
министрлыгының 2016 елның
7 июлендәге 165-ОД номерлы
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының 2014 елның 18 апрелендәге 91-ОД номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының җылылык челтәрләре буенча җылылык энергиясен, җылылык китерү матдәсен тапшырганда технологик югалту нормативларын раслау буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

Административ регламентның 2 бүлегендә:

2.2 пунктта:

«Дәүләт хезмәтен яисә сүз таләпне билгели торган норматив акт» графасында «4.1.63 пп» сүзләрен «4.1.69 пп» сүзләренә алмаштырырга;

2.4 пунктта:

«Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләпнең иseme» графасында «дәүләт хезмәте» сүзләреннән соң «күрсәтүне туктатып тору мөмкинлеге Россия Федерациясе законнарында каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору вакыты» сүзләрен өстәргә;

«Стандартка карата таләпнең эчтәлеге» графасында түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә: «Дәүләт хезмәте күрсәтү срогын туктатып тору каралмаган»;

2.5 пунктта:

«Стандартка карата таләпнең эчтәлеге» графасына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.

Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсе аша тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:

шәхсән (ышаныч кәгазе нигезендә мөрәҗәгать итүче исеменнән эш итүче зат тарафыннан);

кулга тапшыру турында белдереп, заказлы почта юлламасы аша.

Гариза белән документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан көчәйтелгән электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә дә гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, яки Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин»;

2.6 пунктта:

«Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләпнең исеме»

графасында «тапшырырга хокуклы» сүзләреннән соң «, шулай ук аларны мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан алу, шул исәптән электрон формада, аларны тапшыру тәртибе; әлеге белешмәләр алар карамагында булган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма» сүзләрен өстәргә;

2.9 пунктта:

«Стандартка карата таләпнең эчтәлеге» графасында «Аңлатманың» сүзен «Тәртипнең» сүзе белән алмаштырырга;

2.14 пунктта:

«Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына таләп атамасы» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга, мөрәҗәгать итүчеләрнең көтү һәм аларны кабул итү урынына, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турында Россия Федерациясе законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итүгә, мондый хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиа мәгълүматларын урнаштыру һәм рәсмиләштерүгә карата таләпләр»;

«Стандартка карата таләпнең эчтәлеге» графасына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«инвалидлар өчен хезмәт күрсәтелә торган урынга каршылыксыз үтеп керү, шул исәптән объектларга каршылыкларсыз үтеп керү һәм чыгу мөмкинлеге, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында объект буенча мөстәкыйль хәрәкәт итә алу мөмкинлеге тәэмин ителә;

дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла»;

2.15 пунктта:

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасында түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Инвалидларга башка затлар белән бертигез дәрәҗәдә хезмәтләр күрсәтүгә комачаулаган каршылыкларны бетерүдә ярдәм итү.».

3 бүлектә:

3.5 пунктның икенче абзацын төшереп калдырырга;

3.10 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Документлар комплектына кисәтүләр булмаган очракта яки мөрәҗәгать итүче тарафыннан ун көн эчендә кисәтүләр бетерелгәннән соң, белгеч җылылык челтәрләре буенча җылылык энергиясен, җылылык китерү матдәсен тапшырганда технологик югалтулар нормативларын раслау турында боерык проектын әзерләүне гамәлгә ашыра;»;

Өченче абзацта «ун» сүзен «биш» сүзенә алмаштырырга;

3.11 пунктта:

икенче абзацта «бер көн» сүзләрен «дүрт көн» сүзләренә алмаштырырга;

3.12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.12. Бүлек белгече боерык күчермәсен имза кую өчен министр урынбасарына җибәрү өчен, бүлек җитәкчесе һәм идарә җитәкчесе белән

алдан килештереп, теркәү хатын әзерли.


Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач бер көн дәвамында гамәлгә ашырыла.


Процедураның нәтиҗәсе: карар белән теркәү хаты яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында белдерү.».


3 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы тарафыннан җылылык челтәрләре буенча җылылык энергиясен, җылылык китерү матдәсен тапшырганда технологик югалту нормативларын раслау буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына 3 нче кушымта

**ҖЫЛЫЛЫК ЧЕЛТӘРЛӘРЕ БУЕНЧА ҖЫЛЫЛЫК ЭНЕРГИЯСЕН, ҖЫЛЫЛЫК КИТЕРҮ МАТДӘСЕН ТАПШЫРГАНДА ТЕХНОЛОГИК ЮГАЛТУ НОРМАТИВЛАРЫН РАСЛАУ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ ХЕЗМӘТЕ КҮРСӘТЕЛГӘНДӘ ГАМӘЛЛӘР ЭЗЛЕКЛЕЛЕГЕ БУЕНЧА БЛОК-СХЕМА**




Бүлек белгече
Җылылык челтәрләре буенча җылылык энергиясен, җылылык китерү матдәсен тапшырганда технологик югалту нормативларын раслау турында эш
Тикшерелгән документлар
документлар тур килсә
Бүлек белгече
Тапшырылган материалларның Тәртиптә куела торган таләпләргә туры килүенә анализ ясый. Нормативны раслау турында боерык проекты әзерли
5 көн
Нормативларны раслау турында боерык проекты
Бүлек җитәкчесе – идарә җитәкчесе – министр урынбасары
Әзерләнгән проектларны карый һәм килештерә. 1 көн
Килештерелгән проектлар
Нормативны раслау турында боерык проекты
Министр
Нормативларны раслау турында боерыкка кул куя
4 көн
Бүлек белгече
Теркәлә торган хат әзерли
1 көн
Министр урынбасары – Бүлек җитәкчесе – идарә җитәкчесе – министр урынбасары
документлар туры килмәсә
Бүлек белгече
Мөрәҗәгать итүчегә кисәтүләрне бетерү кирәклеге турында хәбәр итә
Белдерү
кисәтүләр 10 көн эчендә – бетерелмәгән
Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, белдерү проектын әзерли
1 көн
Баш тарту турында белдерү проекты
Министр урынбасары
Белдерүне килештерү
1 көн
Белдерү
Эш башкару бүлеге белгече
Белдерүне терки һәм мөрәҗәгать итүчегә җибәрә




Административ регламентка (белешмәлек) кушымтаны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы тарафыннан җылылык челтәрләре буенча җылылык энергиясен, җылылык китерү матдәсен тапшырганда технологик югалту нормативларын раслау буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына (белешмәлек) кушымта

Җылылык энергиясе, җылылык китерү матдәсен тапшырганда технологик югалту нормативларын раслау буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган һәм дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшерүдә тоту өчен җаваплы вазыйфаи затларның реквизитлары

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары - Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры | 299-10-07 | mpt@tatar.ru |
| Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары | 210-05-05 | mpt@tatar.ru |
| Энергетика идарәсе җитәкчесе | 210-05-21 | Guzyal.Sadrieva@tatar.ru |
| Энергетика һәм электр энергетикасы бүлеге җитәкчесе | 210-05-22 | Elena.Titova@tatar.ru |
| Эшчәнлек башкару бүлеге җитәкчесе | 292-16-72 | Habibullina.R@tatar.ru |
| Энергетика һәм электр энергетикасы бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе | 210-05-35 | Radel.Minnikaev@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты

| | | |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының сәнәгать бүлеге җитәкчесе урынбасары | 264-77-28 | Alfred.Saliev@tatar.ru». |